СОВЕТ
БУТЛЕРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ
БУТЛЕРОВКА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

## Решение

**от 27.06.2024г.** **№ 63**

**«Советның 19.11.2014 ел, №99 Бутлеровка авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат бирү хакындагы Нигезләмәне раслау турында, шулай ук Бутлеровка авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәр,чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат тапшыруы турында Карарына үзгәрешләр кертү турында»**

«Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 25 гыйнварындагы 71 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Бутлеровка авыл җирлеге советы карар чыгарды:

1.Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 99 номерлы карарына 3 нче кушымтаның 6 нчы бүлегенең 6.2 пунктындагы 13 нче искәрмәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"<13> Әгәр дә мондый акчаларның гомуми суммасы кешенең, аның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының хисап чорында һәм аннан алдагы ике елдагы гомуми кеременнән артып китсә, хисап чоры өчен счетларга кергән акчалар суммасы күрсәтелә. Чит ил валютасындагы счетлар өчен суммалар Россия Банкының хисап датасына курсы буенча рубльдә күрсәтелә.".

2.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Алексеевск муниципаль районы**
**Бутлеровка авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **И.Л.Хушанова**